**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**_2021елның 28 гыйнвары** **104 номер**

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында " 2019 елның 6 мартындагы 498 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының 2020 елга көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2020 елның 18 декабрендәге беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында, Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында " 2019 елның 6 мартындагы 498 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

2. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган Гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары вәкаләтле органга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә биргәндә бирелә дип билгеләргә.»;

2-4 пунктларны 3-6 пунктлары белән санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Г. Карсаловка йөкләргә.

Җитәкче А.А. Новиков